КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 февраль г.Казань № 178

Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеләргә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләрен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актлар кабул итүгә вәкаләтле итеп билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән норматив хокукый актлар бюджет һәм автоном учреждениеләргә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый

актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»  2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары белән расланган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләргә туры килергә тиеш дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2016 ел,  30 декабрь, 1052 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2016 ел,  30 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 08 август, 646 нчы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин